КЫЗЫМА

# Әлфия

*Кәрим Гыйльманов сүзләре*




тын ка-быз-дын, өз - гә - лә - нә ү - зә - гем.
p
Әл - фи - ям— куз ну - рым, син ми-нем йө-рәк жы - рым.
Әл - фи - ям— гөл - чә - чәк,
си-не сө - еп гом(е) - рем ү - тә - чәк.

1955

Кашың кара, буең зифа,
Сөрмәле зур күзләрең.
Мәхәббәт утын кабыздың,
Өзгәләнә үзәгем.

Кушымта:
Әлфиям — күз нурым,
Син минем йөрәк җырым.
Әлфиям — гөлчәчәк,
Сине сөеп гомерем үтәчәк.

Сугыш бетеп илгә кайттым,
Өметем синдә иде.
Әйттермәдең — үзең әйтмәдең
Сөям, дип, син мине.

Кушымта.

Көтмәгәндә син югалдың,
Калды ярсый ятим күңлем.
Әйт, бәгърем, әйт, акыллым,
Мине кемнән ким күрдең?

Кушымта.